ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД НАБЕРЕЖНЫЕ ЧЕЛНЫ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ЯР ЧАЛЛЫ ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

25 декабря 2020г. № 7324

Башкарма комитетның «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына Яр Чаллы шәһәре муниципаль казнасын тәшкил итә торган күчемсез милеккә карата төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына карата төзелгән җир участокларын арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләү буенча йөкләмәләрен үтәүне кичектереп тору мөмкинлеге бирү турында» 2020 елның 20 маендагы 2335 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында

«Икътисадның тотрыклы үсешен тәэмин итүгә һәм яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәләрен булдырмауга юнәлдерелгән кичектергесез чаралар күрү максатларында Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 8 июнендәге 166-ФЗ номерлы Федераль законның 23 статьясы, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында аеруча зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Россия Федерациясе Хөкүмәтенең кайбер актларына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 11 июлендәге 1032 номерлы карары, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2020 елның 6 августындагы 1497-р номерлы, 2020 елның 14 августындагы 1536-р номерлы боерыклары нигезендә

К А Р А Р  Б И Р Ә М:

1. Башкарма комитетның «Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына Яр Чаллы шәһәре муниципаль казнасын тәшкил итә торган күчемсез милеккә карата төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына карата төзелгән җир участокларын арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләү буенча йөкләмәләрен үтәүне кичектереп тору мөмкинлеге бирү турында» 2020 елның 20 маендагы 2335 номерлы карарына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 пунктны яңа редакциядә бәян итәргә:

«1. Кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларына, социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар - иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына кертелгән социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар – иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүчеләргә Яр Чаллы шәһәре муниципаль казнасын тәшкил итә торган күчемсез милеккә карата

төзелгән муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәләре, Яр Чаллы шәһәре муниципаль милкендәге җир участокларына һәм дәүләт милке чикләнмәгән җир участокларына карата төзелгән җир участокларын арендалау шартнамәләре буенча аренда түләүләрен түләү йөкләмәләрен үтәүне 01.04.2020 елдан 01.10.2020 елга кадәрге чор өчен аренда түләве күләмендә кичектереп тору мөмкинлеге бирергә, «Халыкны һәм территорияләрне табигый һәм техноген характердагы гадәттән тыш хәлләрдән саклау турында» 1994 елның 21 декабрендәге 68-ФЗ Федераль законның 11 статьясы нигезендә 2020 елда Татарстан Республикасы Президенты тарафыннан Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертү турында карар кабул ителгәнчегә кадәр, түбәндәге шартларны үтәп:

1) кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының бердәм реестрына кертелгән кече һәм урта эшмәкәрлек субъектларының, социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар – иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүчеләр реестрына кертелгән социаль юнәлешле коммерцияле булмаган оешмалар – иҗтимагый файдалы хезмәтләр күрсәтүчеләрнең (алга таба – арендатор) Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертелгән датага торышы буенча аренда түләүләрен түләү буенча үтәлмәгән йөкләмәсе юк;

2) кичектереп тору мөмкинлеге бирелә торган аренда түләүләренең суммасы 01.01.2021 елдан башлап, әмма 01.01.2023 елдан соңга калмыйча, арендатор тарафыннан тәкъдим ителгән срокта, этаплап, айга бер тапкырдан еш түгел, күләме аренда шартнамәсе буенча ярты айлык аренда түләве күләменнән артмаган бертигез түләүләр белән, яисә аренда шартнамәсен срогыннан алда өзгәндә берьюлы түләнергә тиеш;

3) кичектереп тору сәбәпле чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки Арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле (шул исәптән мондый чаралар аренда килешүендә каралган очракларда) җаваплылык чаралары кулланылмый;

4) арендага алучы тарафыннан кичектереп торуга бәйле рәвештә арендатор тарафыннан түләнергә тиешле өстәмә түләүләр билгеләү рөхсәт ителми;

5) аренда шартнамәсенә карата кичектереп тору шартлары аренда шартнамәсе буенча аренда түләүләрен кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешү төзү датасына бәйсез рәвештә кулланыла.»;

2) түбәндәге эчтәлектәге 1.1. пункт өстәргә:

«5) Татарстан Республикасы территориясендә югары әзерлек яки гадәттән тыш хәл режимы кертү датасына торышы буенча, исемлеге Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында аеруча зыян күргән Россия икътисады тармаклары исемлеген раслау турында» 2020 елның 3 апрелендәге 434 номерлы карары белән расланган, яңа коронавирус инфекциясе таралу нәтиҗәсендә хәл начараю шартларында аеруча зыян күргән Россия икътисады тармакларында эшчәнлекне гамәлгә ашыручы, 2020 елның апреле-июне өчен аренда түләве буенча аренда шартнамәсе буенча аренда түләвеннән азат ителү рәвешендә ташлама бирелгән арендаторга, әлеге карарның 1 пунктында күрсәтелгән шартлар үтәлгәндә, 01.07.2020 елдан 01.10.2020 елга кадәрге чор өчен аренда түләве күләмендә аренда түләүләре күләмен түләү буенча йөкләмәләрне үтәүне кичектереп тору мөмкинлеге бирелә.»;

3) 3 пунктның 1 пунктчасын яңа редакциядә бәян итәргә: «1) арендатор мөрәҗәгать иткән көннән башлап җиде эш көне эчендә аренда шартнамәсе буенча аренда түләүләрен кичектереп торуны күздә тоткан өстәмә килешү проектын Башкарма комитетның финанс идарәсе, хокук идарәсе тарафыннан килештерүне һәм әлеге проектны арендага бирүченең вәкиле тарафыннан имзалауны тәэмин итәргә;»;

4) 1 нче, 2 нче кушымталарны әлеге карарга кушымтада каралганча яңа редакциядә бәян итәргә.

2. Башкарма комитетның эш кәгазьләрен алып бару идарәсенә әлеге карарны «Челнинские известия», «Шәһри Чаллы» газеталарында бастырып чыгаруны һәм аны «Интернет» челтәрендә Татарстан Республикасы рәсми хокукый мәгълүмат порталында (www.pravo.tatarstan.ru), Яр Чаллы шәһәренең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итәргә.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Башкарма комитет Җитәкчесе урынбасары, финанс идарәсе башлыгы С.Р. Мулюковага, Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы Л.Р. Гыйззәтуллинга йөкләргә.

Башкарма комитет
Җитәкчесе Ф.Ш. Салахов

Башкарма комитетның
2020 елның 25 декабрендәге
7324 номерлы карарына
кушымта

Башкарма комитетның
2020 елның 20 маендагы
2335 номерлы карарына
1 нче кушымта

2020 елда күздә тотылган аренда түләвен кичектереп тору
һәм аны 2021-2022 елларда түләү шартлары турында
________ елның №____ муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәсенә
№_____ өстәмә килешү

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе, «Арендага бирүче» дип аталучы, Нигезләмә һәм __________ елның № _____ ышаныч язуы нигезендә Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты исеменнән эш итүче Башкарма комитетының җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы ______________________ исеменнән, һәм __________________________, «Арендатор» дип аталучы, __________________________ нигезендә эш итүче ______________________________ исеменнән, бергә «Яклар» дип аталучылар, түбәндәгеләр турында әлеге өстәмә килешүне төзеделәр:

1. Яклар, ________ елның №____ муниципаль мөлкәтне арендалау шартнамәсенең (алга таба – Шартнамә) гамәлдә булуы кысаларында, Башкарма комитетның 2020 елның 20 маендагы 2335 номерлы карары нигезендә, Арендаторга 01.04.2020 елдан 01.10.2020 елга кадәр чорга түбәндәге шартларда аренда түләвен түләүне кичектереп тору мөмкинлеге бирелү турында килештеләр:

- 01.04.2020 елдан 01.10.2020 елга кадәр чорда түләү каралган айлык аренда түләве (алга таба – кичектерелгән аренда түләве) Арендатор тарафыннан Шартнамәгә әлеге өстәмә килешүнең 2 пунктында билгеләнгән тәртиптә 01.01.2021 елдан башлап 31.12.2022 елга кадәр түләнә.

2. Кичектерелгән аренда түләве Арендатор тарафыннан 20___ елның _______ башлап хисап аеның соңгы числосыннан соңга калмыйча, акчаларны _______ (_____) сум күләмендә бертигез түләүләр белән (2021-2022 елларда Шартнамәнең гамәлдә булу срогына бәйле рәвештә) ________________ бюджетына (_____________ исәп-хисап счетына) күчерү юлы белән, 2021-2022 елларда түләнә (түләүләр графигы нигезендә).

Кичектерелгән аренда түләвен түләү күләме Шартнамә буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан арта алмый.

3. Шартнамә буенча, 2021-2022 елларда түләнергә тиешле айлык аренда түләве Шартнамәдә каралган срокларда Арендатор тарафыннан аерым түләүләр белән түләнә.

4. Арендатор кичектерелгән аренда түләвенең калган өлешен ________________ бюджетына (_____________ исәп-хисап счетына) срогыннан алда күчерергә яки акчаларны кичектерелгән аренда түләвенең аннан соңгы түләүләре исәбенә кертергә хокуклы.

5. Кичектереп тору сәбәпле 01.04.2020 елдан 01.10.2020 елга кадәрге чорда, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки Арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле, шул исәптән аренда шартнамәсендә каралган җаваплылык чаралары кулланылмый.

6. Шартнамәне срогыннан алда өзгәндә, Арендатор 2020 елда мөлкәттән фактта файдалану срогы өчен кичектерелгән аренда түләвен, Шартнамәне өзгән датадан башлап биш календарь көн эчендә, берьюлы тулы күләмдә Арендага бирүчегә түли.

7. Шартнамәнең башка шартлары үзгәрешсез кала.

8. Әлеге өстәмә килешү бер үк төрле юридик көчкә ия булган ______ нөсхәдә төзелде.

9. Әлеге өстәмә килешү Яклар тарафыннан имзаланган вакыттан башлап үз көченә керә һәм ___________ елның № _________ Шартнамәнең аерылгысыз өлеше булып тора.

9[1] Әлеге өстәмә килешү хокукларны теркәү органында дәүләт теркәвенә алынган вакыттан башлап үз көченә керә һәм ___________ елның № _________ Шартнамәнең аерылгысыз өлеше булып тора.

Якларның имзалары:

«Арендатор»
____________________________________
телефон: ___________________________
Адрес: _____________________________
Исәп-хисап/счеты ___________________
Банк ______________________________
ИНН ____________, БИК ____________,
ОГРН ______________, КПП _________

Җитәкче

___________________ ________________
м.у.

«Арендага бирүче»
«Яр Чаллы шәһәре
муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты» МКУ
423805, Яр Чаллы шәһәре,
Х. Туфан проспекты, 23 йорт

Башкарма комитетның җир һәм мөлкәти мөнәсәбәтләр идарәсе башлыгы

___________________________
м.у.

---

[1] Шартнамә бер елга яки аннан күбрәк срокка төзелгән очракта кертелә.

Башкарма комитетның
2020 елның 20 маендагы
2335 номерлы карарына
2 нче кушымта

2020 елда күздә тотылган аренда түләвен кичектереп тору
һәм аны 2021-2022 елларда түләү шартлары турында
________ елның №____ җир участогын арендалау шартнамәсенә
№_____ өстәмә килешү

«Татарстан Республикасы Яр Чаллы шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты» муниципаль казна учреждениесе, шәһәр Уставы нигезендә эш итүче Башкарма Җитәкчесе ______________________ исеменнән, «Арендага бирүче» дип аталучы, һәм __________________________, «Арендатор» дип аталучы, ___________________________ нигезендә эш итүче ______________________________ исеменнән, бергә «Яклар» дип аталучылар, түбәндәгеләр турында әлеге өстәмә килешүне төзеделәр:

1. Яклар, ________ елның №____ җир участогын арендалау шартнамәсенең (алга таба – Шартнамә) гамәлдә булуы кысаларында, Башкарма комитетның 2020 елның 20 маендагы 2335 номерлы карары нигезендә, Арендаторга 01.04.2020 елдан 01.10.2020 елга кадәр чорга түбәндәге шартларда аренда түләвен түләүне кичектереп тору мөмкинлеге бирелү турында килештеләр:

- 01.04.2020 елдан 01.10.2020 елга кадәр чорда түләү каралган айлык аренда түләве (алга таба – кичектерелгән аренда түләве) Арендатор тарафыннан Шартнамәгә әлеге өстәмә килешүнең 2 пунктында билгеләнгән тәртиптә 01.01.2021 елдан башлап һәм 31.12.2022 елга кадәр түләнә.

2. Кичектерелгән аренда түләве Арендатор тарафыннан 20___ елның _______ башлап хисап аеның соңгы числосыннан соңга калмыйча, акчаларны _______ (_____) сум күләмендә бертигез түләүләр белән (2021-2022 елларда Шартнамәнең гамәлдә булу срогына бәйле рәвештә) ________________ бюджетына (_____________ исәп-хисап счетына) күчерү юлы белән, 2021-2022 елларда түләнә (түләүләр графигы нигезендә).

Кичектерелгән аренда түләвен түләү күләме Шартнамә буенча айлык аренда түләвенең яртысыннан арта алмый.

3. Шартнамә буенча, 2021-2022 елларда түләнергә тиешле айлык аренда түләве Шартнамәдә каралган срокларда Арендатор тарафыннан аерым түләүләр белән түләнә.

4. Арендатор кичектерелгән аренда түләвенең калган өлешен ________________ бюджетына (_____________ исәп-хисап счетына) срогыннан алда күчерергә яки акчаларны кичектерелгән аренда түләвенең аннан соңгы түләүләре исәбенә кертергә хокуклы.

5. Кичектереп тору сәбәпле 01.04.2020 елдан 30.06.2020 елга кадәрге чорда, чит акчалардан файдаланган өчен штрафлар, процентлар яки Арендатор тарафыннан аренда түләвен кертү тәртибен һәм срокларын үтәмәүгә бәйле, шул исәптән аренда шартнамәсендә каралган җаваплылык чаралары кулланылмый.

6. Шартнамәне срогыннан алда өзгәндә, Арендатор 2020 елда мөлкәттән фактта файдалану срогы өчен кичектерелгән аренда түләвен, Шартнамәне өзгән датадан башлап биш календарь көн эчендә берьюлы тулы күләмдә, Арендага бирүчегә түли.

7. Шартнамәнең башка шартлары үзгәрешсез кала.

8. Әлеге өстәмә килешү бер үк төрле юридик көчкә ия булган ______ нөсхәдә төзелде.

9. Әлеге өстәмә килешү Яклар тарафыннан имзаланган вакыттан башлап үз көченә керә һәм ___________ елның № _________ Шартнамәнең аерылгысыз өлеше булып тора.

9[2] Әлеге өстәмә килешү хокукларны теркәү органында дәүләт теркәвенә алынган вакыттан башлап үз көченә керә һәм ___________ елның № _________ Килешүнең аерылгысыз өлеше булып тора.

Якларның имзалары:

«Арендатор»

___________________________________

телефон: ___________________________

Адрес: _____________________________

Исәп-хисап/счеты ___________________

Банк ______________________________

ИНН ____________, БИК ____________,

ОГРН ______________, КПП _________

Җитәкче

___________________ ________________

м.у.

«Арендага бирүче»

«Яр Чаллы шәһәре
муниципаль берәмлеге
Башкарма комитеты» МКУ
423805, Яр Чаллы шәһәре,
Х. Туфан проспекты, 23 йорт

Башкарма комитет
Җитәкчесе

___________________________

м.у.

Башкарма комитет Аппараты Җитәкчесе урынбасары, эш кәгазьләрен алып бару идарәсе башлыгы вазыйфаларын башкаручы — А.Ф. Бареева

[2] Шартнамә бер елга яки аннан күбрәк срокка төзелгән очракта кертелә.